**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районының**
**Арча шәһәр муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, Арча ш. Совет майданы, 27**
**тел. 3-16-25, 3-12-35**

**Муниципальное образование**
**город Арск**
**Арского муниципального района**
**Республики Татарстан**
**Совет города Арск**
**422000,г. Арск, площадь Советская , 27**
**тел. 3-16-25, 3-12-35**

**Арча шәһәр Советы**

**карары**

**« 04 » октябрь 2016 ел** **№ 45**

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Арча шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 24.04.2004 ел, № 23-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре»муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Арча шәһәре Башкарма комитетының «референдум үткәрү инициативасы турында» 27.09.2016 ел, №134 карары, Арча шәһәре Советының 28.09.2016 ел, №44 «Референдум үткәрү инициативасы турында» карары нигезендә, Арча шәһәр Советы карар бирде:

1. 2016 елның 20 ноябренә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2.Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Арча шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә, алар өчен түләү күләме 100 сум тәшкил иткән 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы инвалидларыннан һәм анда катнашучылардан тыш, һәм акчаны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

- Урам утларын ремонтлау (торак пунктларда яктырткычларны алыштыру һәм урнаштыру): Арча шәһәре: Зур, Банк, Комсомол урамнары;

-РКУ 250-400 терекөмешле лампалы яктырткычларны ЖКУ-150 натрий лампалары булган лампаларга һәм ВЛ 0,4 кВ тимер-бетон терәкләрне монтажлап үз-үзен тота торган изоляцияләнгән чыбыкларга урнаштыруга алмаштыру (5 линия): торак пунктларда: Арча шәһәре (урам

Маршал Жуков, Пушкин, М. Мәһдиев, Астрономия,.Зәйнуллина, Гагарина,М. Горький,Төзүчеләр,Ибраһимов,Чулпан,Ямашев, Нагорная, Кол Гали,К. Тинчурина, Г. Сафиуллин ,Березинка,Күл,Тополиная,Болын, Кленовая ур., Лесная ур., Урман урамы, 1-нче, 2-нче, 3-нче, 4-нче, 5-нче Урман тыкрыгы; Иске Айван авылы (Югары,Механизаторлар, Яшьләр, Түбән тан, Фуат Мансуров, Мәктәп урамнары); Күпербаш авылы (Киров, Мичурин, Яр буе, Свердлов, Татарстан, Үзәк, Мәктәп, Зур Бирәзә ( м. Вахитов, Газовиклар, Җиңү, Татарстан, г. Тукай урамнары);

- Арча шәһәрендә чишмә территорияләрен төзекләндерү (Вахитов ур.-4, Ямашев ур.-1);

-Арча шәһәренә (Азин, Г. Сафиуллин, Көньяк, м. Гафури, Чулпан, Җиңүгә 65 ел, Кояшлы, Т. Гыйззәт, 9 Май, Яңа, Ф. Әмирхан, Татарстан, 1Совет, Кәримов, Ямашев урамнары)юлларга таш җәю;

Васильева Божа (Магистраль, Ш.Мәрҗани ур.); Иске Айван авылы (Югары, Кече Айван ур.); Күпербаш авылы( Яшьлек урамы); Зур Бирәзә (Газовиклар урамы).

Аерым мәсьәләләр буенча экономияләнгән очракта, акчаны Арча шәһәре Башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә рөхсәт итәргә.

ӘЙЕ ЮК

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмати стендларда урнаштырырга: Башкарма комитетның административ бинасы (Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27 йорт); район мәдәният йорты (Арча шәһәре, Совет мәйданы, 25 йорт); КФҮ (Арча шәһәре, Һ.Такташ урамы, 58 йорт); Плодосовхоз авыл клубы (Арча шәһәре, Кленовая урамы, 4); үзәк китапханә (Г. Арча, Банк ур., 2а).

4.Әлеге карар бастырылган көннән үз көченә керә.

Арча шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе И.Г. Нуриев

«Совет города Арск»